**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «8» апреленнән № 20-164

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 1 апрелендәге 689-Р номерлы карары белән расланган 2020 елда Татарстан Республикасында икътисадый үсеш белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген һәм эшлекле активлык дәрәҗәсен арттыру буенча беренчел чараларны гамәлгә ашыру чаралары планының 14 пункты, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты ГХАТ бүлегенең «әйдәп баручы белгече» вазыйфасы язылган 28 нче юлны төшереп калдырырга;
- «мәгълүмат куркынычсызлыгы секторы» исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «мәгълүмат белән тәэмин итү һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы секторы».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов